ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.5, с.
Ямбулатово,
422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур. 5 нче йорт, Ямбулат авылы,
422587

Тел.: (84379) 36-5-18 факс: (84379) 36-5-18

19 ноября 2022г. № 1

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районыЯмбулат авыл җирлегенең Казыльяры авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяры авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 6800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?- Казыльяры авылына юл салу өчен вак таш сатып алу һәм кайтару, дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 19 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 5 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 5 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен - 5 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен - 0 катнашучы тавыш бирде, 0 җыенда катнашучы - тыелып калды.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяры авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяры авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяры авылында 6800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?- Казыльяр авылына юл салу өчен вак таш сатып алу һәм кайтару, дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяр авылында гражданнарның җыены нәтиҗәләрен Ямбулат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: А.Н.Макаров